ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.06.2019 г.Мензелинск № 602

"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертү турында".

08.10.2018 елдагы "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының идарәчелек карамагындагы муниципаль учреждениеләренең, муниципаль казна учреждениеләренең һәм муниципаль унитар предприятиеләрнең уставларына (нигезләмәләренә) һәм тиешле учреждениеләр (предприятиеләр) җитәкчеләре һәм эшләүчеләре белән хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче һәм китерү мөмкин булган хезмәт вазифаларын башкарганда шәхси кызыксынучанлык килеп чыгу турында аларның хәбәр итү бурычын билгеләүче мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен тәртипкә салучы үзгәрешләрне кертү турында"гы №1136 карары, шулай ук 25.12.2008 елдагы "Коррупциягә каршы тору турында"гы №273-ФЗ нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Р.Х.Каһиров исемендәге Аю төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәреш кертергә.

1.1. Түбәндәге эчтәлектәге 7 нче бүлекне өстәргә: "Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу".

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район муниципаль бюджет гомумибелем бирү учреждениесе директоры Ф.Х.Фарраховны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле итеп билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче К.Р.Нәҗмиев.